МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

ПК-3 Казан шәһәре № 16.02.2016

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын били торган затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында кушымтада бирелә торган нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүенең барлык очраклары турында язмача рәвештә кушымтада (2 нче кушымта) бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә хәбәр итәргә.
3. Кадрлар бүлегенә (С.Н.Афанасьева) Министрлык хезмәткәрләрен әлеге боерыгы белән кул куйдыртып таныштырып чыгарга һәм әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры**
**урынбасары – министр** **Р.А.Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2016 елның 16.02.2016 № ПК-3 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-Фз номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указы нигезендә эшләнде. Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясен (алга таба – Комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына һәм әлеге Нигезләмәгә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыкларына таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып түбәндәгеләргә булышлык күрсәтү тора:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008

елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;

Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга бәйле мәсьәләләрне карый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш).

1.5. Министрлыкта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасы бозылу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## 2. Комиссиянең составы

2.1. Комиссиянең составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары арасыннан министр билгеләп куя торган Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия сәркатибе һәм әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары да карарлар кабул ителгәндә тигез хокукларга ия була. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия сәркатибе), кадрлар бүлегеннән һәм Министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү секторыннан, Министрлыкның башка бүлекчәләреннән министр билгели торган дәүләт хезмәткәрләре.

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсеннән һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсеннән вәкил;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле булган фәнни оешмалардан, һөнәри белем бирү оешмаларыннан, югары белем бирүче мәгариф оешмаларыннан һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан вәкил (вәкилләр).

2.3. Министр Комиссия составына Министрлык каршындагы иҗтимагый совет, Министрлыкның беренчел һөнәри берлек оешмасы һәм Министрлыкта

оештырылырга мөмкин булган ветераннарның иҗтимагый оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә министр гарызнамәсе нигезендә тиешле оешмалар белән килешү буенча кертелә.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәгән Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген калдырмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәшмә тавыш хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу мәсьәләсе Комиссиядә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры башлыгы һәм Комиссия рәисе билгели торган, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын, үзенә карата Комиссиядә әлеге мәсьәлә каралачак дәүләт хезмәткәре биләгән аналогик вазыйфаларны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссиядә карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан вазыйфаи затлар; мәнфәгатьле оешмаларның вәкилләре; үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу мәсьәләсе комиссиядә карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле, – һәр конкрет очракта үзенә карата Комиссиядә әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең яисә Комиссиядәге теләсә кайсы әгъзаның үтенеч язуы нигезендә Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн калганчы комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә торган карар буенча.

2.8. Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы булып санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар уздыру рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасында Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә кыеклатып шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгәндә, ул бу хакта утырыш башланганчыга кадәр хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

а) дәүләт хезмәткәрләре тапшырган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булу-булмавына һәм дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча министрның түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын тапшыруы:

дәүләт хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;

б) Министрлыкның норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кадрлар бүлегенә килгән түбәндәгеләр:

Министрлык боерыгы белән расланган, Министрлыкта аларны биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Министрлыкның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфаи биләүгә хезмәт яисә граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгате, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса, дәүләт хезмәтеннән куылган көннән соң ике ел узганчы;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үзенең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган дәүләт хезмәткәренең чит ил дәүләте законнарына ярашлы рәвештә, әлеге чит ил органнарының компетентлы органнары тарафыннан салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яисә үзенең ихтыярына яки үзенең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән шартларга бәйле рәвештә, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында белдерүе;

в) министрның яисә Комиссиядәге теләсә кайсы әгъзаның дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә яисә Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга кагылышлы йогынты акты;

г) министрның дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләрнең төгәл яисә тулы булмаган рәвештә тапшырылуы турында таныклаучы тикшерү материалларын тапшыруы;

д) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Министрлыкка коммерциячел яисә коммерциясез оешмадан килгән, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки граждани-хокукый шартнамә төзү турында белдерү, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның Министрлыкта вазыйфаны биләгән вакытта үтәгән вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса, күрсәтелгән гражданинга Комиссия тарафыннан элегрәк әлеге оешма белән хезмәт яисә граждани-хокукый мөнәсәбәтләргә керүдән баш тарту яисә мондый гражданинга аның коммерциячел оешмада яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенә яки аның граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруына ризалык бирү турында мәсьәләнең Комиссиядә каралмаган булуы шарты белән.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин тарафыннан Министрлыкның кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган датасы, яшәгән урыны буенча адресы, дәүләт хезмәтеннән куылган көнгә кадәр соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерциячел яки коммерциясез оешманың аталышы, урнашкан урыны, эшчәнлегенең холкы, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән вакытта гражданин тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычлар, коммерциячел яки коммерциясез оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләр, шартнамә төре (хезмәт яисә граждани-хокукый), аның күздә тотылган гамәлдә булу чоры, шартнамә буенча эшләрне башкарган (хезмәтләрне күрсәткән) өчен түләү суммасы. Кадрлар бүлегендә мөрәҗәгать карала, аның нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча нигезләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылырга мөмкин һәм әлеге Нигезләмәгә туры китереп, Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәр кадрлар бүлегендәге коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында нигезләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

3.5. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта күрсәтелгән хәбәр Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан карала, ул хәбәрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында аталган мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «д» пунктчасында аталган хәбәрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмәне әзерләгәндә Министрлыкның кадрлар бүлеге вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьне яисә белдерүне тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздыру, аннан язмача аңлатмалар алу хокукына ия, ә министр яисә аның махсус шуңа вәкаләтле урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала. Мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.

3.7. Комиссия рәисе үзенә Комиссия утырышын уздыру өчен нигезләре булган мәгълүмат кергән очракта:

а) 10 көнлек чорда Комиссия утырышы датасын билгели. Бу вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 3.8 һәм 3.9 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат килгән көннән соң 20 көнгә саңга калып билгеләнә алмый;

б) үзенә карата Комиссиядә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлүе турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын, Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар бүлегенә килгән мәгълүмат белән, шулай ук аталган мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктының «б» пунктчасында аталган затларны Комиссия утырышына чакыру турында үтенеч язуларын карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм утырыш барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризаны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән чор узган көннән соң бер ай узганчы уздырыла.

3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерү, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.

3.10. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин катнашында карала. Дәүләт хезмәткәре яисә гражданин Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасына ярашлы рәвештә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә күрсәтә.

3.11. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яисә гражданин юклыгында уздырылырга мөмкин, түбәндәге очракларда:

әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында күрсәтелмәсә;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм тиешле рәвештә аның уздырылу вакыты һәм урыны турында хәбәр алган дәүләт хезмәткәре яисә гражданин Комиссия утырышына килмәсә.

3.12. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яисә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.13. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында үзләренә мәгълүм булган белешмәләрне таратырга хокуклы түгел.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданинның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында нигезләмәгә туры китереп дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;

б) әлеге пунктның беренче абзацында аталган Нигезләмәгә туры китереп дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә тотуга карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәгәнлеген билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәмәгәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәүнең ярамаганлыгы турында күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

б) гражданинга коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирмәскә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса, һәм мондый карарны нигезләргә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив һәм хөрмәткә лаеклы дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив һәм хөрмәткә лаеклы түгел дип танырга.

Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъльк яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив булмавын һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып торуын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» федераль закон таләпләрен үтәргә комачаулаучы шартларның объектив һәм хөрмәткә лаеклы булуын танырга;

б) «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны,

нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» федераль закон таләпләрен үтәргә комачаулаучы шартларның объектив һәм хөрмәткә лаеклы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгының булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) министрга мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча яки аның барлыкка килүенә юл куймау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгәнлеген танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

3.20. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.21. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның керемнәре чыгымнарына туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 статьясының 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын танырга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның керемнәре чыгымнарына туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 статьясының 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм (яки) тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә һәм (яки) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны, компетенцияләренә туры китереп, прокуратура органнарына һәм (яки) бүтән дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.22. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аңа коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

б) аның хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенең һәм (яки) коммерциячел һәм коммерциясез оешмада эшләр башкаруының (хезмәтләр күрсәтүенең) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12

статьясы таләпләрен бозуын билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр җиткергән оешмага мәгълүмат ирештерергә киңәш итә.

3.23. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» башлап «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15, 3.17 - 3.19 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.24. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның норматив хокукый актлары проектлары, министр карарлары яисә йөкләмәләре әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә министрга карау өчен тапшырыла.

3.25. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия бүтәнчә карар кабул итмәсә), утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларыннан алынган тавышларның гади күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.26. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куя. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карардан тыш, Комиссия карарлары министр өчен киңәш бирү холкына ия була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри булып тора.

3.27. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре;

б) үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, ата исемен күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең тәгъбирләнеше;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелә торган дәгъвалар, аларга нигез булган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта катнашкан затларның фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка килгән датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.28. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы үз фикерен язмача формада бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә зарури тәртиптә кушып куелырга һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышып чыгарга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көне узганнан соң 7 көнлек чорда – министрга, тулысынча яки аннан өземтәләр рәвешендә –

дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары нигезендә бүтән мәнфәгатьле затларга җибәрелә.

3.30.Министр комиссия утырышы беркетмәсен карарга бурычлы һәм үз компетенциясе кысаларында, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның бүтән мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә анда булган киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен карау һәм кабул ителгән карар турында министр язмача формада Комиссиягә үзенә Комиссия утырышы беркетмәсе килгән көннән башлап бер айлык чорда хәбәр итә. Министр карары Комиссиянең киләчәк утырышында әйтелә һәм фикер алышуларсыз игътибарга алына.

3.31. Комиссия дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар хата кылу билгеләрен ачыклаган очракта, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында мәсьәләне хәл итү өчен бу хакта министрга мәгълүмат җиткерелә.

3.32. Комиссия дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яисә җинаять составын үз эченә ала торган гамәл кылуы фактын (гамәл кылмау фактын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлнең кылынуы (гамәл кылынмавы) турында мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3 көнлек чорда, ә зарурлык булганда – кичекмәстән, хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

3.33. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан алынган өземтә үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлүе турында мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә кушып куела.

3.34. Комиссия карарыннан комиссия сәркатибенең имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган өземтә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданинга кул куйдыртып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча комиссиянең тиешле утырышы уздырылган көннән соң бер эш көне узганчы, белдерүле заказлы хат итеп җибәрелә.

3.35. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техника ягыннан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, аның датасы, вакыты һәм уздырылу урыны турында мәгълүмат җиткерү, Комиссия әгъзаларын комиссия утырышында сөйләшү өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру кадрлар бүлегендәге коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.11.2016 Казан шәһәре № МК-284

**министрлыгында вазыйфа биләү һәм элемтә коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы указларын үтәү максатларында боерык бирәм:

граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфалар биләргә һәм (яки) бер ай дәвамында граждани-хокукый шартнамә (граждани-хокукый шартнамәләр) шартларында йөз мең сумнан артык бәягә әлеге оешмада эшләр башкарырга (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтергә) хокуклы, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса;

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында әлеге боерыкның 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән хезмәт шартнамәләрен яки эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турында граждани-хокукый шартнамәләр төзегән вакытта эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр тапшырырга тиеш;

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин тарафыннан дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң әлеге боерыкның 2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында каралган таләпләрне үтәмәү әлеге гражданин белән төзелгән шартнамәне туктатуга китерә.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 18 июлендәге ПК-15 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер министры урынбасары –**
**министр** Р.А.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2016 елның
04.11.2016 № 01-236 боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа билгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

министрның беренче урынбасары
министр урынбасары

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

министр ярдәмчесе

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр идарәчесе
бүлек башлыгы

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

сектор мөдире
әйдәп баручы киңәшче
әйдәр баручы консультант

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

әйдәп баручы белгеч
I разрядлы өлкән белгеч

МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2015 Казан шәһәре № П-259

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Кушымтага туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезлә расларга.
2. Кушымтага туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы каршындагы иҗтимагый советның 10 кешедән торган санын һәм аның составын расларга.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Ю.Н.Багровны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.А. Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2015 елның
23.12.2015 № 11-289
боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ КАРШЫНДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы каршында иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының (алга таба – Министрлык) мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган киңәшләшү органы булып тора, ул мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләткә карамаган коммерциясез оешмаларның хокукларын, сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү, аларның нәтиҗәлелеге һәм куркынычсызлыгы, халыкка хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча дәүләт системасын камилләштерүгә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне дә гамәлгә ашыра.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Министр боерыгы нигезендә раслана.

1.3. Үзенең эшчәнлегендә Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары киңәш итү характерына ия.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгатьчелек башлангычларында гамәлгә ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эше ирекле нигездә, ачык булу һәм партнерлык принципларында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына катгый рәвештә туры китереп корыла.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданлык җәмгыяте институтлары вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының уртак кызыксынучанлыгы нигезендә башкара.

## 2. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

2.1. Иҗтимагый советның төп эшчәнлек максатлары:

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм үтәгәндә гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый оешмаларның һәм дәүләткә карамаган бүтән коммерциясез оешмаларның хокукларын яклау;

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсенә кагыла торган мәсьәләләрдә дәүләт сәясәтендәге төп юнәлешләрне эшләү буенча иҗтимагый, һөнәри һәм иҗат берләшмәләре вәкилләрен җәлеп итү, Министрлык эшчәнлелегендә хәбәрдарлык һәм ачык булу принцибын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт (муниципаль) хезмәтләре сыйфатына иҗтимагый контрольне көчәйтү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр әзерләү;

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсенә кагыла торган мәсьәләләргә бәйле норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру, шул исәптән Министрлыкта эшләнә торган дәүләт программалары проектлары турында фикер алышу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлыкның төп эшчәнлек юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлык дәрәҗәсен үстерү;

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләренә карап, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисади, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып үзгәртелергә һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ СОСТАВЫ

3.1. Министрлык каршындагы иҗтимагый совет рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм гражданнарның, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет әгъзаларыннан төзелә. Иҗтимагый советның шәхси составы Министр тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә иң киме 5 һәм иң күбе 30 кешелек составта формалаша.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмаларның һәм башка төрле социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның вәкилләре керә ала. Шул ук вакытта аларның профессиональ сыйфатлары, шул исәптән тиешле белемнәре, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр хакында сөйләшкәндә зарури булган әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән берлектә, Иҗтимагый совет составына Иҗтимагый состав әгъзаларының гомуми санынннан

яртысын тәшкил иткән күләмдә Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән затлар да кертелә.

Иҗтимагый совет составына Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан биштән бер өлешеннән артмаган күләмдә элегрәк Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт вазифаларын, муниципаль вазифаларны һәм муниципаль хезмәт вазифаларын биләгән затлар кертелә ала.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче, суд карары нигезендә хокукый сәләтсез дип танылган затлар, хөкеме юкка чыгарылмаган яисә кире алынмаган затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары булып тора алмаган башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан сайлана, әгәр дә алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Министр мөрәҗәгате буенча карап тикшерелә, шулай ук Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризасы яки Иҗтимагый совет әгъзаларының биштән бер өлешенең тәкъдиме буенча карап тикшерелә.

Әгәр аның өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, карар кабул ителгән булып санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

ул Иҗтимагый совет составынннан чыгу турында гариза тапшыргач;

сәламәтлегенең торышы буенча аның Иҗтимагый совет эшендә эшкә сәләтсез булуы, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшүе яки башка сәбәпләр аркасында;

аңа карата чыгарылган гаепләү турында суд карары законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул эшкә сәләтсез яки сәбәпсез юк булучы дип танылганда;

аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылганда – Иҗтимагый совет утырышында катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар нигезендә;

Россия Федерациясе гражданлыгы беткәндә;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч мәртәбәдән артык) Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмаганда;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (ике мәртәбәдән артык) Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының боерыкларын үтәмәгәндә;

ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына һәм бүтән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

аның тарафыннан икенче гражданлык алынган очракта.

3.7. Иҗтимагый советта әгъза булуны туктату Министрның Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы нигезендә яисә Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының күрсәтмәсе нигезендә кабул ителгән карары нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге буенча эшчәнлек башкарырга сәләтсез булганда, аңа карата гаепләү турында суд карары законлы көченә кергәндә, Россия Федерациясе гражданлыгы беткәндә, Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәисе урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Министр карары нигезендә Иҗтимагый совет рәисенең күрсәтмәсе нигезендә туктатыла, түбәндәге очракларда:

аңа карата Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаеп тагылганда;

аңа карата административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

аны дәүләт хакимияте органының закон чыгару (сайлаулы) депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлаулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле вазыйфасына кандидат буларак теркәгәндә, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кертелгән очракта.

## 4. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт серен, шәхси белешмәләр турында мәгълүматларны һәм аннан файдалану чикле булган мәгълүматны тәшкил итүче мәгълүматтан файдалануга бәйле рәвештә федераль законнарда аларга үтеп керү чикләнә торган чаралардан кала, Министрлык инициативасы белән үткәрелүче барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәл»ләрдә һ.б.) катнашырга;

инициатив тәртиптә Иҗтимагый советка аналитик язулар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү һәм җибәрү;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертү;

Иҗтимагый совет утырышына көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерүдә катнашу өчен чакырылучы затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертү;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгу.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләрне бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне үтәү;

әлеге Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый советның эш тәртибен белү һәм үтәү;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашу;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан төзелүче эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшендә катнашу.

## 5. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисенең күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышында расланучы планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзаларының, Иҗтимагый совет рәисенең һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер мәртәбәдән дә ким булмаган күләмдә үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы белән Министрлык тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актларның проектларына һәм Министрлыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрелә торган норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирү максатларында да үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр анда Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы була. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын яки үз фикерен язмача, факсимиль яки электрон почта аша, бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә яки Иҗтимагый совет рәисенең урынбасарына, яки Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибенә алдан хәбәр итеп, Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыра ала. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары санына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актларның проектларын (норматив хокукый актларны) Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерү Министрлык аларны Иҗтимагый советка җибәргән көннән башлап ун календарь көне дәвамында башкарыла. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирүне

үткәрү, сораштыру нәтиҗәләрен Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаганда Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертеп, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын читтән торып сораштыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка төрле, тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең дөреслеген һәм аларның документаль дәлилләнүен тәэмин итә торган элемтә чарасы ярдәмендә документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта, рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә, тавыш бирү датасына кадәр җиде календарь көненнән дә соңга калмыйча соңгысы буенча Иҗтимагый совет бәяләмә бирергә тиеш. Зарурлык килеп туган очракта Иҗтимагый совет әгъзалары карап тикшерелә торган норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) буенча Министрлыктан өстәмә материалларны һәм мәгълүматларны соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары тавышларның гадәти күпчелеге нигезендә кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын – Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаган очракта Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә кабул ителүче карарлары тәкъдим характерына ия һәм Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Иҗтимагый совет карары буенча башка төрле ысул белән кызыксынган затлар игътибарына җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлык сайтында "Органнар һәм оешмалар" бүлегендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тапшыра;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет тәкъдимнәренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның башка документларына имза сала;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрүнең вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән гарызнамәләргә, тәкъдимнәргә, киңәшләргә, җавапларга, аңлатмаларга һәм мөрәҗәгатьләргә имза сала;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итүгә кирәкле башка вазыйфаларны башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмый торган чорда соңгысының вазыйфаларын башкара;

Иҗтимагый совет утырышларына әзерлекне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны раслау өчен Иҗтимагый совет рәисенә тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисенең әмере буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган башка вазыйфаларны башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышлар өчен материаллар һәм карарларның проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышын үткәрүнең урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында Иҗтимагый совет әгъзаларына хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Министрлыкның оешкан рәвештә хезмәттәшлек итүен тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин итүне башкара;

Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары белән килештереп, Иҗтимагый совет утырышларында мәсьәләләрне тыңлауга һәм фикер алышуга әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм башка төрле эш органнарына берләшергә, материалларны әзерләү өчен Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет тарафыннан каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар һәм белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып саналмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкин.

5.13. Иҗтимагый совет карап тикшерүенә тапшырыла торган материаллар Иҗтимагый совет рәисенең урынбасарына аларны карап тикшерү планлаштырылган Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны тагын да соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру ягыннан Министрлык тәэмин итә.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2015 елның
23.12.2015 № 17-259
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет составы

| | |
|---|---|
| Беседина Раиса Петровна | Татарстан Республикасы Элемтә хезмәткәрләре һөнәр берлегенең республика комитеты рәисе; |
| Бикмуллин Марат Габделгазиз улы | «Мәгълүмат системалары» ҖЧҖ директорлар советы рәисе; |
| Гайфуллин Марат Муллаәхмәт улы | «ТаксНет» ЯАҖ генераль директоры; |
| Галиев Марат Гадый улы | Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Д□□л□т Советы депутаты, Татарстан Республикасы Д□□л□т Советыны□ Икътисад, инвестициял□р □□м эшкуарлык комитеты р□исе урынбасары; |
| Гарифуллин Раиф Равил улы | Халыкара элемтә академиясенең Казан бүлеге рәисе, «Таттелеком» ГАҖ баш инспекторы; |
| Җәләлов Ринат Гыйният улы | «Сайда» ҖЧҖ икътисад мәсьәләләре буенча консультанты; |
| Китаева Наталья Николаевна | «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДБҺБУ директоры; |
| Королев Андрей Владимирович | ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «ТР Мәгълүматлаштыру академиясе каршындагы кризиска |

| | |
|---|---|
| | каршы процедураларның нәтиҗәлелеген арттыру үзәге» төбәк иҗтимагый фонды идарәсе рәисе; |
| Рыбушкин Николай Николаевич | Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Казан (Идел буе) федераль университетының җинаять хокукы кафедрасы доценты; |
| Шакиров Марат Мансур улы | «МТС» ГАҖ Татарстан Республикасындагы филиалы директоры. |

Министерство информатизации и связи Республики татарстан

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.07.2013 № МК-15

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы указларын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре

хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга (кушымтада бирелә).

2. Билгеләргә:

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфалар биләргә һәм (яки) бер ай дәвамында граждани-хокукый шартнамә (граждани-хокукый шартнамәләр) шартларында йөз мең сумнан артык бәягә әлеге оешмада эшләр башкарырга (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтергә) хокуклы, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса;

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында әлеге боерыкның 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән хезмәт шартнамәләрен яки эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турында граждани-хокукый шартнамәләр төзегән вакытта эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр тапшырырга тиеш;

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин тарафыннан дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң әлеге боерыкның 2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында каралган таләпләрне үтәмәү әлеге гражданин белән төзелгән шартнамәне туктатуга китерә.

3. Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2010 елның 20 гыйнварындагы П-6 номерлы;

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2010 елның 20 гыйнварындагы П-6 номерлы боерыгына өстәмәләр кертү турында» 2010 елның 17 сентябрендәге П-109 номерлы;

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 20 маендагы ПК-9 номерлы.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**Министр** **Р.А.Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2013 елның
17.07.2013 № ПК-15
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Министрның беренче урынбасары
2. Министр урынбасары
3. Министр ярдәмчесе
4. Эшләр идарәчесе
5. Бүлек башлыгы
6. Сектор мөдире
7. Әйдәп баручы киңәшче
8. Әйдәп баручы белгеч
9. Әйдәп баручы консультант
10. I разрядлы өлкән белгеч

МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2015 Казан ш. № 07-210

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында**

"Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Хокукый тәэминат секторына (И.Г. Евченко) , дәүләт теркәвенә алу өчен, боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ю.Н.Багровка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **Р.А.Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2015 елның 23.11.2015 № П-210 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының норматив-хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив-хокукый актларының проектларына (алга таба – актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны да кертеп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза, коррупциячел факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында, Министрлык актларының әзерләнә торган проектларына хокукый экспертиза үткәрү һәм Министрлыкның кабул ителгән актларына мониторинг үткәрү вакытында үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган актларга, актларның проектларына карата үткәрелми.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.

1.5. Министрлыкта актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны оештыруда төп принциплар булып түбәндәгеләр тора:

1) актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең мәҗбүрилеге;

2) актны башка норматив-хокукый актлар белән үзара бәйләнештә бәяләү;

3) актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезлелеге, объективлыгы һәм тикшерелүчәнлеге;

4) актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүче затларның компетентлылыгы;

5) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затларының гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүе.

## 2. Актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы (алга таба – Методика) нигезендә уздырыла.

2.2. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза хокукый тәэмин итү секторының вәкаләтле заты тарафыннан үткәрелә.

2.3. Хокукый тәэмин итү секторына кергән актларның проектлары килгән көнендә Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза журналында (алга таба – Журнал) (1 нче кушымта) теркәлә.

Вәкаләтле зат тарафыннан аларны куллануга мониторинг уздырганда коррупциячел факторларны ачыклаганда актлар коррупциячел факторларны ачыклау көнендә журналда теркәлә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт проекты Журналда теркәлгәннән соң биш көн эчендә үткәрелә.

2.5. Актка һәм акт проектына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре хокукый тәэмин итү секторының вәкаләтле заты бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә, аны хокукый тәэмин итү секторы җитәкчесе имзалый.

2.6. Актта коррупция факторлары ачыкланган очракта, бәяләмәдә (2 нче кушымта) Методика нигезендә ачыкланган барлык коррупция факторлары чагылдырыла.

Бәяләмәдә актта ачыкланган коррупция факторларын бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булырга тиеш.

Кул куелганнан соң, эш көне дәвамында, хокукый тәэмин итү секторы мөдире тарафыннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрына (алга таба - министр) җибәрелә.

2.7. Министр актта коррупция факторлары булуы турындагы бәяләмә нәтиҗәләре буенча аңа үзгәрешләр кертү яки аны үз көчен югалткан дип тану турында карар кабул итә.

2.8. Актны эшләгән структур бүлекчә өч көн эчендә ачыкланган коррупция факторларын бетерү максатында үзгәрешләр кертү турында Министрлык акты проектын яисә актны үз көчен югалткан дип тану турында проект әзерли һәм коррупциягә каршы экспертиза өчен хокукый тәэмин итү секторына җибәрә.

2.9. Коррупциягә каршы экспертизага алынган акт проектында коррупция факторлары булган очракта, вәкаләтле зат 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча бәяләмә төзи, коррупция факторлары булмаган очракта, 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча бәяләмә төзи.

Бәяләмә хокукый тәэмин итү секторы мөдире тарафыннан имзалана һәм акт проектын юллаган структур бүлекчәгә җибәрелә.

2.10. Коррупция факторлары булган очракта, акт проектын әзерләгән структур бүлекчә өч көн эчендә акт проектын эшләп бетерергә һәм, яңадан коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен, аны хокукый тәэмин итү секторына җибәрергә тиеш. Коррупциягә каршы яңадан экспертиза өч көн эчендә үткәрелә.

2.11. Эшләнеп беткән акт проектында коррупция факторлары булмаган очракта, вәкаләтле зат бәяләмәне коррупциягә каршы экспертизага юллаган структур бүлекчәгә җибәрә.

2.12. Структур бүлекчә (актны әзерләүче) эшләнеп беткән акт проектын мәнфәгатьле структур бүлекчәләр җитәкчеләренең визалары белән имзалау өчен министрга җибәрә.

2.13. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда теркәлә.

2.14. Министр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә актны (акт проектын) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коррупциягә каршы экспертизага җибәрергә хокуклы.

## 3. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Министрлык тарафыннан эшләнгән һәм Министрлыкның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге www.mic.tatarstan.ru рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштырылган, рәсми рәвештә бастырып чыгарылган Министрлык актлары һәм актлары проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

3.2. Министрлык актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе, акт проекты карау өчен хокукый тәэмин итү секторына җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.

3.3. Сайтта урнаштырылган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

3.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән бәяләмә (алга таба - бәяләмә) карау өчен Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә җибәрелә.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим характерына ия һәм Министрлык тарафыннан зарури карап тикшерелергә тиеш. Бәяләмәне алган көннән соң 15 көнлек чорда Министрлыкның структур бүлекчәсе килгән бәяләмәне карый һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны үткәргән юридик яки физик затка, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел

факторларны юкка чыгару ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, нигезле җавап җибәрә.

3.6. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе тарафыннан Тәртипнең 3.5 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә юкка чыгарыла.

3.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән искәрмәләрне бетергәннән соң һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Министрлыкның актны әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне теркәп, яңадан карау өчен хокукый тәэмин итү секторына тапшыра. Кабат карау өч көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

3.8. Әгәр дә актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Министрлыкның шушы актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Министрлыкта теркәлгән көннән башлап өч көнлек чорда актка үзгәрешләр кертү буенча яки аны көчен югалткан дип тану турында чаралар күрә.

3.9. Министрлык Министрлыкның актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән актларның проектларында коррупциячел факторлар булу турында таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, Министрлык законнарда билгеләнгән тәртиптә аталган актларны (актларның проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

3.10. Документны эшләүче үзе тарафыннан эшләнгән, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, документны эшләүче аталган норматив хокукый актларның проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен кертә.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының норматив хокукый
актларына һәм норматив хокукый
актлары проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру тәртибенә
1 нче кушымта

## Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналы

| **Актны (акт проектын) экспертизага кабул итеп алу датасы** | **Актны (акт проектын) кабул иткән структур бүлекчәнең исеме** | **Актның (акт проекты-ның) аталышы** | **Вәкаләтләрне кабатлау** | **Коррупция нормалары булуы/булмавы** | **Экспертизаны үткәрү вакыты** | **Бәяләмә бирү датасы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** |

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының норматив хокукый
актларына һәм норматив хокукый
актлары проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының хокукый тәэмин
итү секторы

**Коррупциячел факторлар булу турында бәяләмә**

___________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 3 өлеше нигезендә коррупциягә каршы экспертиза уздырылды

_________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Тапшырылган

_________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

коррупция факторлары ачыкланды.

Ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

_________________________________________________________________.

(коррупциячел факторларны юкка чыгару ысулы күрсәтелә)

________________________(вазыйфа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия)

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының норматив хокукый
актларына һәм норматив хокукый
актлары проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру тәртибенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының хокукый
тәэмин итү секторы

**Коррупциячел факторлар булмавы турында бәяләмә**

________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 3 өлеше нигезендә коррупциягә каршы экспертиза уздырылды

____________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Тапшырылган

____________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

коррупциячел факторлар ачыкланмады.

________________________(вазыйфа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия)